| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЮГАРЫ ЛАШЧЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

# КАРАР

«21» май 2018 ел Югары Лашчы авылы № 46-3

ТР Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы «РФ муниципаль хезмәт турында», 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, 01.07.2017 елгы 132-ФЗ номерлы "РФ аерым закон актларының коррупцион хокук бозган өчен ышанычны югалту белән бәйле эштән азат итүне җәза итеп куллану турында мәгълүматны дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасында урнаштыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында" Федераль законнар, 25.06.2013 елгы 50-ЗРТ номерлы "Муниципаль хезмәт турында" ТР Кодексы нигезендә, һәм муниципаль норматив хокук актын законга туры китерү максатында, ТР Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында 07.09.2016 елның 1-17 номерлы карары (23.11.2016 елның 1-22 номерлы, 25.08.2017 елның 2-31 номерлы, 07.11.2017 елның 1-37 номерлы, 04.04.2018 елның 43 номерлы карарлар редакциясендә, 04.04.2018 елның 44 номерлы) белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советының 05.04.2018 елның 43 номерлы карарының 1 пунктында «Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советының 07.11.2017 елның 1-37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» «07.09.2016 елның 1-17 номерлы (25.08.2017 елның 2-31 номерлы карар редакциясендә)» сүзләрен «07.09.2016 елның 1-17 номерлы (23.11.2016 елның 1-22 номерлы, 25.08.2017 елның 2-31 номерлы карарлар редакциясендә)» сүзләренә алмаштырырга;

2. 25 бүлектә:

25.7 пункты, түбәндәге редакциядә биреп, өстәргә:

«25.7 Муниципаль хезмәткәргә карата ышанычны югалту белән бәйле эштән азат итү җәзасын куллану турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтне узган җирле үзидарә органы тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 15 маддәсендә каралган ышанычны югалту белән бәйле эштән азат ителүче затлар реестрына кертелә;

3. 22 бүлектә:

22.3 пунктка, түбәндәге редакциядә биреп, 2 абзац өстәргә:

«Выслуга лет өчен исәпләнгән һәм билгеләнгән пенсия акчасы составына вазифа окладына һәм классы чин өчен вазифа окладына ай саен бирелә торган өстәмә акча керә.».

II. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак.

III. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Югары Лашчы авыл җирлеге Башлыгы Г.Һ. Усманова